**Әни, мин кайттым**

Әни, синең янга кайттым:
“Ярар, кызым, бик әйбәт балам”.
Шушы җылы сүзне ишетер өчен,
Әни, синең янга кайтып барам.

Үзем ашыгам, янам, көям,
Кайт тизрәк, әниең китә, диләр.
Йөрәккәем оча, дөп-дөп тибә,
Нидер булыр кебек, күңел сизә.

Җитешмәдем, юлым озын иде бик,
Күрә алмадың соңгы тапкыр кызыңны син.
Авыр сулап бер алдың да, тынып калдың,
Мәңгелеккә бакыйлыкка китеп бардың...

Тагын кайттым, бүген сиңа менә,
Туган бусагамнан атлап керәм.
Кабер тынлыклары ич биредә,
Син булмагач, әни, шыксыз өйдә.

Бар да үз урынында, үз тәртибе,
Шул ук бүлмә, шул ук түшәк.
Тик түшәк буш, ялгыз, салкын үзе,
Теле булса, әйтер иде назлы сүзне.

Хыялларга чумам, башта төрле уйлар,
Балачаклар истә, узган матур еллар.
Ерак калды, кире кайтмас алар,
Матур мизгел булып сакланырлар.

Шушы изге уйларыма уралып мин,
Кулыма Коръән алам, дога кылам.
Әни рухы шат булсынга, этинеке,
Шушы нигез хуҗалары булган һәркемнеке.

Догаларым ирешәдер кебек сезгә,
Төшләремә кермисез бит берегез дә.
Начар төшләр күрмәсен дип минем балам,
Кабердә дә түзәсең,әни, мин сокланам.

Тормыш бирдең, назлап мине үстердең син,
Кеше иттең, югалтмадың, ташламадың.
Урының булыр һәрчак йөрәгем түрендә.

Тыныч йокла, әни-бәгърем, кабереңдә.

**60 яшь**

Кышкы салкын, буреннардан арынып,
Язла килә туган якларга.
Кояшлы һәм аяз көннәр белән,
Минем юбилейны котларга.

Кышлар узып, ямьле яз башында.
Мин туганмын апрель аенда.
Битлек киеп, бәхет өмет итеп,
Матур, ямьле тормыш башларга.

Шул көннән соң күпме язлар узган,
Күпме еллар артта калганнар.
Сизелмичә узган гомерләр дә,
Алтмышлар да инде тулганнар.

Исән булсын газиз башкайларым,
Исем китми минем алтмышка.
Гомер язларымны саный-саный,
Алга таба атлыйм – җитмешкә.

**Туган нигез**

Туган нигез, туган бусага,
Йөрәккә җылы сүз, якын да.
Һич аңлата алмаслык мәгънә ята.
Шушы газиз сүзләр уртасында.

Уйлап кара әле, шушы нигезләрдә,
Кемнәр туган, кемнәр яшәгән.
Елны еллар алыштырып, гомер узган,
Бер-бер артлы буын алышынган.

Торган нигез ташы нык булса да,
Узылган бит күпме язмыш анда.
Саклый нигез ерак истәлекне,
Тапшырырга яңа буыннарга.

**Алабугам**
Алабугам минем, матур калам,

Урнашкан ул Кама буенда.
Әби-бабаларым дога кылып,
Нигез ташы салган шушында.

Теләгәндер аңа аксакаллар,
Матур кала булып үссен дип.
Кешеләрнең тырышлыгы, уңганлыгы,
Даннар булып илгә күчсен дип.

Үсте, Алабугам, матур булып,
Күпме истәлекләр эчендә.
Геройларны бирде, баш имәде,
Горурланып яшәр мәңгегә!

**Хыял**
Утырдым да киттем хыял дөньясына.
Үткән яшьлегемне сагынып.
Кайда адашты ул, кайда калды,
Ничек кайтырга соң борылып.

Кайтыр идем кабат яшьлегемә.
Кодрәтемнән килсә әгәр дә.
Йөрер идем иркен болыннарда,
Җиләк җыеп ямьле Сәйдәлдә.

Кама өсләреннән ак пароход,
Кычкыртып ла уза кебектер.
Юк, бу тик хыял гына.
Ул тарафка юллар өзектер.

Еллар уза тора, гомер уза,
Чәчләргә дә күптән чал керде.
Мин йөргән яшьлек сукмаклары,
Тапталдылар инде, күмелде.

Үзгәрде шул дөнья, бик үзгәрде.
Борып булмый инде кирегә.
Мин хыялый уйларымда калам.
Ә син ашкынма, йөрәк, тилермә.

**Шигырь язам**
Язның матур бер иртәсе бүген,
Таң беленеп килә, аяз күгем.
Торып утырдым да, илһамланам,
Шигырь язам, үзем дулкынланам.

Башта матур уйлар, изгелекләр,
Шигырь булып ак юлларга тезеләләр.
Күпме яшәп, күпме күрелде лә,
Шул хисләрне шигырь итеп тезәм менә.

Яшәгәндә төрле вакыт була икән,
Балачак та, үсмер чак та, картлык килә.
Ничек аны шигырь итеп язмыйсың да.
Бик күр хатирәләр башларымда.

Шигырь язам -үзем елыйм, үзем көләм,
Газиз баштан үткәннәрне санап тезәм.
Кояшлы да, болытлы да булды еллар.
Шул мизгелләр шигыремә әвереләләр.

Язгы иртә, торып утырдым да,
Шигырь язам, уем еракларда.
Ак болытлар арасыннан чүпләп алам,
Уй-фикерләр тезеп шигырь язам.

**Пинәрә**

Табигатьнең матур өлешендә,
Болын уртасында иде Пинәрә.
Яр буенда камыш, таллар үсеп,
Утыралар кебек бүген дә.

Пинәрәнең зур болыннарында,
Җир җиләкләренең исләре.
Яшел камыш төпләрендә үскән,
Җуа суганнары тәмнәре.

Хәтеремдә калды ул мәңгегә,
Онытылмаслык булып гомергә.
Су астында ятса да йөргән юллар.
Хатирәләр мәңге сакланырлар.

**Язмышлар**

Язмышлар бит гүя аккошлардай,
Аерылалар төрле якларга.
Таралышып, янып ялкыннарда,
Кала алар мизгел сакларга.

Ә язмышлар, ә язмышлар төрле.

Болындагы чәчәкләр кебек,
Төсләре дә, хисләре дә төрле,
Өметле дә, өметсез дә кебек.

Һәркем йөрәгендә ул язмышлар,
Тирән эзләр салып үтәләр.
Тормыш дигән олы, озын юлда.
Өмет бирә,  кайчак сүнәләр.

Язмышларны үзгәртмик лә , дуслар.
Кирәк түгел әрнү, янулар.
Очкыннары китәр еракларга,
Соңыннан калыр тирән яралар.

**Талым**
Тәрәзәмнең нәкъ каршысында.
Үсеп килә бер яшь тал.
Һәр яз саен нәни сыерчыклар
Кунып аны мактап сайрыйлар.

Карыйм бүген тәрәзәдән талга.
Ни булган соң, нинди тамаша?
Ботак саен мәче утыра анда.
Ырлашалар алар, мырлаша.

Әй, үзем дә саташканмын әллә.
Анда бит яз, март ич ләбаса.
Яз килгәнен каян белер идең.
Шул мәчеләр әгәр булмаса.

**Әй, бу дөнья**
Кызык та соң бу дөнья дигәннәре,
Кемнәр яши, кемнәр сөйрәлә.
Аңлый алмассыңдыр аны, дускай.
Син сөйләмә миңа, сөйләмә.

Бу дөньяда тормыш итүләре,
Кемгә әче, кемгә ул төче.
Шул тәмнәрне татып карар өчен,
Үзебезме түгел йөрүче?

Дөнья көтәбез дип тырышып-тырышып,
Көнне төнгә ялгап яшибез.
Инде яшәр көчең, хәлең беткәч,
Әй, яшәргә тагын бер, дибез!

**Мәчекә**

Бар минем бер кече дустым,
Мәчекә дип атала.
Бу исемне аңа үзем куштым,
Аны сөеп, яратып мактарга.

Төн җитүгә барлык җаннар йоклый,
Ул йокламый, нидер эзләнә.
Хуҗа бит ул өйдә, сакта тора.
Шулай һәр төн нидер искәрә.

Көндезләрен бераз ял итәм дип,
Мәчекәем минем тәгәри.
Юк, тукта әле, кемдер ишек шакый.
Күзләмичә аны ярамый.